РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
**Исполнительный комитет**
**Нижнерусского сельского поселения.**
**С. Нижняя Русь, ул. Г. Ахметова, 39**
**Тел/факс: 3-72-15**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма**
**комитеты.**
**Түбән Урәс авылы, Г. Ахметов урамы, 39**
**Тел/факс: 3-72-15**

Кукмара муниципаль районы
Тубэн Урэс авыл Башкарма комитеты

КАРАР

«17» февральындагы 2025 ел № 22

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубэн Урэс авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка кире кайтару тыелган урыннарны раслау һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубэн Урэс авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка кире кайтару тыелган урыннарны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубэн Урэс авыл җирлеге территориясендәге хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кире кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче ОГРН 1061675011045 ИНН 1623008521 В.Г.Сафаров

Түбән Үрәс авыл башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка кире кайтару тыелган урыннар**

1. Балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары.
2. Парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары.
3. Күп фатирлы йортлар янәшәсендәге территорияләр, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлары һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковка урыннары, тротуарлар һәм, күп фатирлы йортлар янындагы территорияләргә керә торган юллар барлыкка китерүче автомобиль юлларын да кертеп, автомобиль юллары булган территорияләр.
4. Балалар учреждениеләре, белем бирү һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре.
5. Мәдәният һәм сәнгать объектлары янәшәсендәге территорияләр.
6. Җәмәгать туклануы оешмалары, кибетләр янәшәсендәге территорияләр.
7. Күп кеше йөри торган учреждениеләр янындагы территорияләр.
8. Бию, ял итү һәм буш вакытны үткәрү, массакүләм чаралар үткәрү, мәгълүмат чараларын урнаштыру өчен мәйданчыклар.
9. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.
10. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.
11. Чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган башка территорияләр.
12. Ваклап сату базарлары территорияләре.

Тубән Урәс авыл башкарма комитеты
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубән Урәс авыл җирлеге территориясендәге хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кире кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге**

1. Кукмара муниципаль районы Тубән Урәс авыл җирлеге башлыгы